ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

Постановление
№ 409

Карар
от « 26 » ноября 2019 г.

**Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2019 елның 26 ноябрендәге 1155 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 2019 елның 24 ноябрендәге карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты К А Р А Р Б И Р Д Е:

1. Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга. (карарга теркәлеп килә).
2. Әлеге караны районның «Нократ» («Вятка») газетасында, интернет мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе — Р.М.Гарипов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1051655091080 ИНН1626008865

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре
Башкарма комитетының 2019 ел,
26 ноябрендәге 409 номерлы
карарына
1 нче номерлы кушымта

Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1.Әлеге Тәртип Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәрендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына бәйсез рәвештә, Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, концлагерь тоткыннары, репрессияләнгәннәрдән, күпбалалы гаиләләр (5 һәм аннан күбрәк бала) кала, 2020 елның 28 февраленә кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы «Нократ» («Вятка») газетасында бастырып чыгару һәм http://mamadysh.tatarstan.ru сайтында халыкка игълан итү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәренең шәхси счетына килә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслау булып касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре
Башкарма комитетының 2019 ел,
26 ноябрендәге 409 номерлы
карарына
2 нче номерлы кушымта

БЕЛДЕРҮ (ХӘБӘРНАМӘ) № ________________
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре
шәһәр бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүче Ф. И.А.и.
___________________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________
Сезгә 2020 елның 28 февраленә кадәр бер тапкыр түләнә торган түләүне, түбәндәге чараларны тормышка ашыру:максатында, түләргә кирәк:
- Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерү;
- «Төньяк» поселогында халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүгә оештыру;
- шәһәр урамнарында тротуарлар ясау.Түләү суммасы ________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча:
Алучысы: Татарстан Республикасы буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы)
ИНН 162601001 КПП 162601001
Алучы банкы: ТР Милли банкы Россия Банкы Казан шәһәре БИК 049205001
р/ с. № 40101810800000001
КБК 60511740301300150 ОКТМО 92638101
Түләү билгеләү: җирлек бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары

Җитәкче ____________________ Р. М. Гарипов
М.П. (имза) (имза расшифровка)

------------------- кисеп алу линиясе -----------------------------

Хәбәр (Хәбәрнамә) № ________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
___________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүче Ф. И. О. __________________________________________________
Адрес:
___________________________________________________________
___
Алды«__» ________________ 20__ ел ______________________________________
(түләүченең имзасы)